| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.02.2021 Балык Бистәсе ш.т.п. №31пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2009 елның 29 гыйнварындагы 31пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. "Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2009 елның 29 гыйнварындагы 31пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия ФСХнә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар (авария хәлендәге эшләрдән тыш)»;

2.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

"4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә::

"4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия ФСХнә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар (авария хәлендәге эшләрдән тыш)»;

2.«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»

2019 елның 29 гыйнварындагы 31пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү

турында " 2021 елның 11 февралендәге 29пи номерлы карар үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д. Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов